***Әмирова Роза Мөнировна***
Казан дәүләт медицина университеты, Казан

# КАЗАН ШӘҺӘРЕ ЭРГОНИМНАРЫ БАРЛЫККА КИЛҮДӘ ИҖТИМАГЫЙ-МӘДӘНИ ФАКТОРЛАРНЫҢ РОЛЕ

*Для наиболее полного представления специфики отражения внеязыковой ситуации, в статье рассматривается взаимосвязи различных культур в эргонимическом пространстве г. Казани.*

**Ключевые слова:** *ономастика, эргонимическое пространство, городская лингвокультура, духовная культура.*

*For the most complete submission of the specifics of reflection of the extralinguistic situation, the article examines the relationship of various cultures in ergonomic space of Kazan.*

**Key words:** *onomastics, ergonomic space, urban linguistic culture, spiritual culture*

Ономастик лексиканың кайсы гына төрен алсак та, аларның һәрберсе үзендә халык тарихын, милләт язмышын, мәдәни бәйләнешләрне чагылдыра. Бу күзлектән караганда, эргонимнар аеруча зур роль башкара. Шәһәр тормышында, җәмгыятьтә барган һәр вакыйга, һәр күренеш иң беренче чиратта эргонимда чагылыш таба. Шәһәр лингвокультурасының төп берәмлеге булганлыктан, телара, милләтара бәйләнешләр да иң элек эргонимнарда күзәтелә. Казан шәһәре эргонимнары да күпмилләтле шәһәрдә барган иҗтимагый, мәдәни, динипроцессларны үзендә бик тулы чагылдыра торган берәмлек буларак олы әһәмияткә ия.

Гомумән, соңгы берничә дистә ел эчендә татар эргонимиясенең зур үзгәреш кичерүе күренә. Бу, иң беренче чиратта, илдә барган сәясиижтимагый үзгәрешләр белән бәйле. Сүз ирекe, матбугат ирекe, дин ирекe кайту, халыкта милли рухның уянуы, әлбәттә, Казан шәһәренең эргонимиясенә дә үтеп керә. Һәм Казан шәһәре эргонимиясендә төп урынны алып торган рус яисә интернациональ сүзләргә нигезләнеп ясалган атамалар белән беррәттән, халкыбызның һәм башка төрки телләрнең милли мәдәниятенә, традицияләренә, милли үзенчәлекләренә нигезләнеп ясалган эргонимнар барлыкка килә. Шуның белән бергә, Казан шәһәренә Европа илләре мәдәни һәм матди байлыгының үтеп керә башлавы да татар эргонимиясенә яңа бер төсмер өсти, ягъни илдә барган сәяси, милли, мәдәни үзгәрешләрнең һәрберсе теге яки бу дәрәҗәдә эргонимикада чагылыш таба.

Казан шәһәре элек-электән үзендә Көнчыгыш һәм Көнбатыш цивилизацияләрен берләштергән үзәк булып торган. Шәһәрнең һәрбер атамасы үзендә бик күп милләтләргә хас булган гореф-гадәтләрне,

мәдәни-дини үзенчәлекләрне саклый. Шуңа күрә дә Казан шәһәрендә кулланылышта йөргән эргонимнарны берничә төргә бүлеп карарга мөмкин. Беренче төре – саф татарча эргонимнар. Бу төр эргонимнарда халкыбыз тарихы, мәдәнияте, гореф-гадәтләре, уй-хыяллары, күзаллаулары чагылыш таба. Мәсәлән, *«Сөембикә» кафесының* атамасын алыйк. Сөембикә – халкыбыз тарихында тирән эз калдырган, фаҗигале язмышка ия ханбикә. Ул милләт аңында азатлык, ирек символы, милләт горурлыгы рәвешендә дә күзаллана.Татар халкы өчен бу эргоним чын милли атама буларак кабул ителә.

Чын татарча милли атамалардан тагын «Алтынай» кибетенең, «Милли», «Биләр» кафеларының эргонимнарын китерергә мөмкин. Татарлар тарихында зур урын алып торган Биләр шәһәренең атамасын эргоним ролендә куллану да халкыбызның милли күзаллаулары, үткән тарихы хакында сөйли. «Алтынай» эргонимы шулай ук дини, милли карашлар белән бәйле. Татар халкы өчен ай, алтын ай, иң беренче чиратта, мәчет символы, ә мәчет дини йолаларны, гореф-гадәтләрне үзендә туплаучы, милләтне берләштерүче үзәк булып тора.

*«Ак бүре» кафесының* атамасы исә мифологик карашларга, борынгы Тәңречелек чорына барып тоташа. Г.Ф. Саттаров антропонимикада *бүре* сүзе белән бәйле исем-фамилияләрнең килеп чыгышын борынгы бабаларыбызның тотемистик ышануларына бәйләп аңлата [Саттаров, 1990: 16].

Г.Р. Галиуллина әлеге компонент кергән кеше исемнәренең күптән инде кулланылыштан төшеп калса да, башка төр ономастик берәмлекләрдә, мәсәлән, эргонимнарда актив булуына басым ясый. Галим фикеренчә, бу факт Тәңречелек чорына барып тоташа торган борынгы йола, гореф-гадәтләрнең халкыбыз хәтерендә әле дә саклануы күрсәтә [Галиуллина, 2008: 57].

Милли генә түгел, дини гореф-гадәтләрне, Коръән сүрәләрен чагылдыручы атамалар да Казан шәһәре эргонимиясендә төп урыннарның берсен алып тора. Бу хакта ялгызлык исемнәренең бер төре булган антропонимнарны тикшерүче Г.Р. Галиуллина да үзенең хезмәтләрендә: «В формировании и дальнейшей эволюции тюрко-татарской антропонимической системы как части духовной культуры народа огромную роль сыграла мусульманская религия. Под влиянием мусульманства антропонимическая система тюрко-татар вышла в новый этап развития...» – дип яза [Галиуллина, 2008: 111].

XX гасыр ахырында илдә барган иҗтимагый үзгәрешләр, дин һәм сүз ирекге игълан ителү нәтиҗәсендә эргонимик системада да мөселманлык, ислам дине кануннары белән бәйле эргонимнар барлыкка килде. Мәсәлән, ирләр кием-салымнарын сата торган *«Адәм» кибетенең* атамасы Коръән сүрәләренә, Мөхәммәд пәйгамбәрнең хәдисләренә, атабыз Адәм, анабыз Һәва дигән ышануларга барып тоташа. Гомумән, Казан шәһәре

эргонимиясендә Коръән белән, ислам дине белән бәйле булган атамалар шактый еш күзәтелә. Алар, бер яктан, халкыбызның, дини гореф-гадәтләре, ышанулары хакында бәян итсә, икенче яктан, бу эргонимнар татар халкының ислам дөньясы белән булган багланышлары чагылдыручы тел фактлары булып та торалар. Биредә мисал итеп тагын «Хәләл», «Йасин», «Әл-кәүсәр», «Зәкать», «Корбан» эргонимнарын китерергә мөмкин. Кафе, кибет, медицина үзәкләре, дини оешмаларның атамалары булып хезмәт иткән бу эргонимнар Казан шәһәрендә шактый актив кулланыла торган берәмлекләрдән санала. Мәсәлән, күп кенә кибет, кафеларның, хәләл азык-төлек стандарты буенча комитет атамасы буларак билгеле *хәләл* сүзе олы мәгънәгә ия. Бу лексема безгә гарәп теленнән кергән һәм ул ислам кануннары нигезендә әзерләнгән ризык, ислам дине тарафыннан рөхсәт ителә торган эш-шөгыль мәгънәсендә аңлашыла.

Коръән белән бәйле эргонимнарның тагын берсе – *Әл-Кәүсәр* атамасы. Бу эргоним мөселман кешесенә Коръәндәге 36 нчы аятьнең 108 нче сүрә исеме буларак мәгълүм. Гарәп теленнән алынган бу лексема ислам динендә җәннәт чишмәсенең исемен аңлата. Шулай ук ул муллык, байлык изгелек символы буларак та гәүдәләнә. *Кәүсәр* лексемасы татарларда шактый актив һәм борынгыдан кулланыла.

Дини оешмаларның, берләшмәләрнең атамалары да олы мәгънә салынган гарәп сүзләренә нигезләнгән. Мәсәлән, Татарстан мөселманнарының дини нәзарияте каршында оешкан фондхалкыбызга «Зәкать» исеме белән билгеле. Шушындый атамага ия фонд Татарстанда ислам динен тарату, ислам җәмгыятьләренең үсешен тәэмин итү, мөселманнарга ярдәм күрсәтү максатыннан оешкан. Бу фондның башкара торган эшләрен, үз алдына куйган максат-бурычларын исәпкә алсак, аның шундый тирән мәгънәле атама алуы, һичшиксез, үз-үзен аклый.

Дини гореф-гадәтләрне тормышка ашыру, мөселманнарга ярдәм итү йөзеннән оештырылган дини берләшмәләрнең тагын берсе – *«Корбан» комплексы. Корбан* лексемасы мөселман кешесенең үзаңында *корбан бәйрәме, корбан чалу* кебек дини гореф-гадәтләр белән бергә күзаллана. Һәм бу комплекс та нәкъ менә шул дини йолаларның тормышка ашыру белән шөгыльләнә.

Халкыбыз тормышында ислам диненең, Коръән сүрәләренең, Мөхәммәд пәйгамбәр хәдисләренең йогынтысын күрсәткән эргонимнарның тагын бер төре кеше исемнәре белән бәйле. Казан шәһәрендә антропонимнар нигезендә ясалган эргонимнар күпчелекне алып тора. Ләкин аларның бары берничәсе генә ислам диненә барып тоташа. Болар – *«Айшә», «Мөслимә» кибетләре, «Фатыйма» кунакханәсе һәм хатын-кызларга психологик ярдәм күрсәтү оешмасы, «Рәшидә» Коръән өйрәнү буенча уку-укыту үзәге*.

Югарыда саналган атамаларда, бер яктан, халкыбызның милли үзаңы, дини ышанулары, икенчедән, ислам дине кануннары нигезендә яшәү рәвеше, шуңа омтылышы чагылыш таба. Шунысын да искәртергә кирәк: дин, Коръән белән бәйле мондый атамалар бары тик XX гасыр ахырларында гына, илдә барган зур иҗтимагый процесслар нәтиҗәсендә генә кулланылышка кереп китте һәм активлашты.

Казан шәһәренең көнчыгыш илләре традицияләрен саклаучы, аларның милли-мәдәниүзенчәлекләрен үзендә туплаучы үзәк булуына ишарә иткәнэргонимнарның бер төркеме шулай ук кеше исемнәренә нигезләнеп ясалган. Урта Азия илләрендә киң кулланыла торган антропонимнардан саналган *Нагмир, Сәид, Әсхәр* исемнәре башкалабызда эргоним ролен үти: *«Нагмир» сәүдә комплексы, «Әль-Сәид» күчемсез милек агентлыгы, «Әсхәр» гараж кооперативы.* Кайбер очракларда эргоним буларак кулланыла торган антропоним янына Көнчыгыш илләрдә кешегә мөрәҗәгать иткәндә файдаланыла торган эндәш сүз дә килергә мөмкин. Мәсәлән, «*Давид бәк» кунакханәсе* һ.б.

Кайбер очракларда ил, дәүләт, милләт исемнәре дә эргоним ясауда катнашырга мөмкин. Мәсәлән: *«Turkish airlines», «Туркистан» кафесы, «Үзбекистан һава юллары» авиаоешмасы, «Үзбәк ашлары» кафесы, «Төрек ашлары» кафесы, «Кытай» автомобильләр төзәтү гаражы, «Японка» автомобиль кирәк-ярагы кибете* һ.б. Әлеге саналган оешмаларның эшчәнлеге теге яки бу яклап эргонимнарда чагылыш тапкан милләт белән бәйле. Я алар шул милләтнең ашын-сыен тәкъдим итәләр, яки шул илләрдә чыгарылган машиналарга ремонт ясау, кирәк-ярак сату белән шөгыльләнәләр. Ничек кенә булмасын, әлеге сәүдә нокталарының һәркайсы Казан шәһәренең күпмилләтле кала икәнлеген, көнчыгыш һәм төрки дәүләтләрнең рухи башкаласы булуын күрсәтә.

Шулай ук XX гасыр ахырларында киң кулланыла башлаган эргонимнарның икенче бер төркемендә Европа цивилизациясе чагылыш таба. Теге яки бу оешманың, күп очракта кибетләрнең Европа тәҗрибәсенә нигезләнүенә, яисә Көнбатыштан китерелгән товарлар белән сату итүенә аның чыганак телдәгечә язылган исемнәре – эргонимнары да ишарә итә. Мондый очракларда еш кына товар тамгасы, яисә шул товарны эшләп чыгаручы оешма исеме шул кибетнең атамасы буларак та кулланыла. Аеруча машина маркалары, товар атамалары, ягъни прагматонимнар эргоним ролендә еш очрый. Мәсәлән, «Adidas», «Dayly», «Grostyle», «Honda», «Hyundai», «Nokia», «Siemenes» һ.б. кибетләренең атамалары ролен кием-салым, машина, көнкүреш техникасы маркалары башкара.

Шунысы игътибарга лаек, инглиз, немец, итальян һ.б. телләрдә язылган эргонимнар үзләренең мәгънә үзенчәлекләре ягыннан да аерыла. Аларда Көнбатыш илләренең халыкларына хас булган юмор, сентиментализм, конкретлык чагылыш таба. Мондый төр эргонимнар,

Көнчыгыш иллəрдəн кергəн төрлəренə караганда,бик үзенчəлекле.Аларда дөнья əдəбияты да, кино-театрлар да, миф-легендалар да, Европа халкының дөньяга карашы, аны кабул итүе – барысы да урын ала. Шунысы кызыклы, бу эргонимнарның барысы да инглиз телендə язылган. Гомумəн, инглиз теле, потенциаль клиентларны җəлеп итү максатыннан, эргонимнар составында, рекламада бик актив кулланыла. Һəм ул, гадəттə,теге яки бу кибет, сəүдə үзəге тəкъдим итə торган товарның югары сыйфатлы, модалы, заманча һəм Европадан кертелгəн булуына ишарə итə.

Югарыдан күренгəнчə, татар эргонимиясе илдəге һəрбер сəяси-иҗтимагый вакыйганы, күпмиллəтле Казан шəһəренең мəдəни-рухи тормышын, дини гореф-гадəтлəрне, милли йолаларны чагылдыра алуы ягыннан олы əһəмиятkə ия ономастик тармак булып тора.

**Чыганаклар**


1. Атласи, Һ.М. Себер тарихы. Сөен-бикə. Казан ханлыгы / Һ. М. Атласи. – Казан: Татар. кит. нəшр., 1993. – 446 б.
2. Əл-Кайси М.И. Ислам əхлагы һəм гадəтлəре / М.И. Əл-Кайси. – Казан: «Иман» нəшр., 1994. – 120 б.
3. Галиуллина, Г.Р. Татарские личные имена в контексте лингвокультурных традиций / Г.Р. Галиуллина. – Казань: Изд-во Казан. ун-та, 2008. – 352 с.
4. Саттаров, Г.Ф. Татар антропонимикасы / Г.Ф. Саттаров. – Казан: Тат. кит. нəшр., 1990. – 276 б.
5. Фахрутдинов, Р.Г. История татарского народа и Татарстана / Р.Г. Фахрутдинов. – Казань: Магариф, 1995. – 255 с.



***Батталова Алсу Дамировна***
***Җəүһəрова Фəнзилə Хəкимовна***
Республика традицион мəдəниятне үстерү үзəге, Казан


## ТАТАРЛАРДА МАЛ АСРАУГА БƏЙЛЕ ТРАДИЦИЯЛƏР: ИСЛАМ ДИНЕ АСПЕКТЫНДА


*Статья подготовлена в рамках поддержанного РГНФ и Правительства Республики Татарстан научного проекта №16-14-16024 а(р)*



*В данной статье рассматриваются животноводческие традиции татар в поверьях и обрядах в свете трансформации исламсокй религии.*



**Ключевые слова:** *ислам, молитва, скотоводство, поверье, обряд.*



*This article discusses the Tatars' farming traditions in their beliefs and rituals in a view of the Islam's transformation.*



**Key words:** *Islam, prayer, farming, belief, ritual.*